**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**15 октябрь 2020 ел** **12-нче номер**

**Биектау авыл җирлеге Советы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел 28 апрелендәге 346-нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары, Биектау авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советы,

**КАРАР КЫЛА:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 апрелендәге 346 номерлы «җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карары (Советның 2018 елның 24 сентябрендәге 425 номерлы, 2018 елның 28 декабрендәге 468 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкыр арттырырга.

2. 2020 елның 1 октябреннән Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында «Биектау авыл җирлеге Советының 2018 ел 28 апрелендәге 346 номерлы (Советның 2018 елның 24 сентябрендәге 425 номерлы, 2018 елның 28

декабрендәге 468 номерлы карары редакциясендә) белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнгән вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

3. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, әлеге карарның 2 пункты нигезендә, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләмен 1,03 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11498 сум күләмендә билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 апрелендәге 346 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карары белән расланган 2 нче кушымтаны (Советның 2018 елның 24 сентябрендәге 425 номерлы, 2018 елның 28 декабрендәге 468 номерлы карары редакциясендә), таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләкләре күләме»:

| Вазифа | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 9 группа |
| Авыл җирлеге башлыгы | 21393 |

5. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырып халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз өстемә алам.

Совет рәисе
Биектау авыл җирлеге Башлыгы Ю.М.Галимов